КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 декабрь г.Казань № 1193

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2020 ел, 15 февраль, 112 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2020 ел, 15 февраль, 112 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегендә:

1 бүлектә:

1.1 пунктның 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.1 пунктның 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.1 пунктның 8 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 10 – 12 пунктчалар өстәргә:

«10) «Татарстан Республикасы Балтач районы Чутай авылы янында 1000 баш савым эре мөгезле терлеккә исәпләнгән сөт-товар фермасы төзү» («Кызыл юл» АХҖК, Балтач муниципаль районы);

11) «Татарстан Республикасы Балтач районы Иске Салавыч торак пункты янында 800 баш савым эре мөгезле терлеккә исәпләнгән сөт-товар фермасы төзү» («Татарстан» АХП» ҖЧҖ, Балтач муниципаль районы);

12) «Татарстан Республикасы Кукмара районының Трыш авылы янында урнашкан 960 баш сыерны карап тотырга һәм саварга исәпләнгән сөт-товар фермасы төзү («Вахитово» ҖЧҖ, Кукмара муниципаль районы);

13) «Татарстан Республикасы Кукмара районының Югары Кузмес авылында савым эре мөгезле терлекләр өчен 1500 башка исәпләнгән сөт-товар фермасы төзү» («Рассвет» агрофирмасы» АХҖК, Кукмара муниципаль районы);

14) «Буа муниципаль районының Кайбыч авыл җирлегендә савым эре мөгезле терлекләр өчен 800 башка исәпләнгән терлекчелек комплексы төзү» («Авангард» ҖЧҖ, Буа муниципаль районы);

15) «Татарстан Республикасы Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылында сыерларны тоту һәм саву өчен 1000 башка исәпләнгән сөт-товар фермасы төзү» («Ленин исемендәге нәсел заводы АХҖК», Әтнә муниципаль районы);

16) «Арча муниципаль районының Иске Чүриле торак пунктында саву залы булган 1200 башка исәпләнгән савым эре мөгезле терлекләр өчен терлекчелек комплексы төзү» («Яңарыш» агрофирмасы ҖЧҖ, Арча муниципаль районы);

17) «Татарстан Республикасы Мөслим районының Уразмәт торак пунктында 2400 башка исәпләнгән сөтчелек комплексы төзелеше» («Август-Мөслим» ҖЧҖ, Мөслим муниципаль районы);

18) «Татарстан Республикасы Актаныш районының Чишмә торак пунктында 1000 башка исәпләнгән сөтчелек комплексы төзелеше» («Чишмә» агрофирмасы» ҖЧҖ, Актаныш муниципаль районы);

19) «Татарстан Республикасы Алексеевск районы Юеш Көрнәле торак пунктында 1340 башка исәпләнгән сөтчелек комплексы төзелеше» («Родина» колхозы, Алексеевск муниципаль районы);

20) «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районындагы «Саба» ҖЧҖенең 60 - 65 тонна/сәгать җитештерүчәнлекле азык-төлек үзәге төзү» («Саба» ҖЧҖ, Саба муниципаль районы);

21) «Татарстан Республикасы Мамадыш районы Тавели торак пунктында 5760 башка исәпләнгән сөт токымлы эре мөгезле яшь терлекләр үстерү һәм симертү буенча махсуслаштырылган ферма» («Азык-төлек программасы» АСК» ҖЧҖ, Мамадыш муниципаль районы);

22) «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Харино авылында 50 гектар мәйданда тамчылы сугару системасы белән җимеш бакчасы булдыру, җиләк-җимеш саклагычлары һәм яшелчәсаклагычлар төзү» («БИО-АГРО» ҖЧҖ, Югары Ослан муниципаль районы)»;

1.3 пунктының 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3 пунктның 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) «Бөртекле һәм майлы культураларны бер мәртәбә 100 мең тоннага кадәр саклау өчен элеватор төзү» («Август-Элеватор» ҖЧҖ, Бөгелмә муниципаль районы)»;

1.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:

«11) «Каталитик крекинг урнаштыру» (В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, «ТАНЕКО» АҖ, Түбән Кама муниципаль районы)».»;

1.11 пунктның 10 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.14 пунктының 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) «Пациентларны күппрофильле медицина тернәкләндерүе үзәге» («Премиум Строй-Инвест» ҖЧҖ, Казан шәһәре).»;

1.15 пунктка түбәндәге эчтәлекле 27 - 31 пунктчалар өстәргә:

«27) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә хосусый индустриаль парк булдыру» («Ромекс Кубань» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

28) «Зеленодольск» сәнәгать мәйданчыгы территориясендә «Вайлдберриз» ҖЧҖ технопаркын төзү («Вайлдберриз» ҖЧҖ, Зеленодольск муниципаль районы);

29) «Казан шәһәренең С.Хәким урамындагы концертлар залы булган күпфункцияле комплекс» («ТАТКРАВТИНВЕСТ» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

30) «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында «Ак Барс» мәчеләренең сирәк төрләрен өйрәнү үзәге төзелеше» («Ак Барс» мәчеләренең сирәк төрләрен өйрәнү үзәге» ДАУ, Кама Тамагы муниципаль районы);

31) Төбәк квалификация комиссиясе беркетмәләре нигезендә сайлап алынган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларында катнашучылар тарафыннан югарыда күрсәтелмәгән, гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган инвестиция проектлары.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин